**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
***БУА ШӘҺӘРЕ***
***БУА***
***МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***
***БАШЛЫГЫ***

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
***ГЛАВА***
***ГОРОДА БУИНСКА***
***БУИНСКОГО***
***МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА***

# КАРАР
# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

22 сентябрь 2020 ел № 9

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Буа шәһәренең 16:14:101002 кадастр кварталы территориясен
планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча ачык ( гавами)
тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы, Буа шәһәр Советының 1998 елның 18 ноябрендәге 2-29 номерлы карары белән расланган «Буа муниципаль районы Буа шәһәрендә җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә» нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәренең 16:14:101002 кадастр кварталы территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.
2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы сайтында Буа муниципаль районы Буа шәһәренең 16:14:101002 кадастр кварталы территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча материалларны урнаштырырга.
3. 2020 елның 22 сентябреннән 22 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәренең 16:14:101002 кадастр кварталы территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча материаллар экспозициясен оештырырга.
4. 1нче кушымта нигезендә, керүче тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә һәм расларга.
5. ТР, Буа ш., Космовский ур., 91Б. адресы буенча 2020 елның 26 октябрендә 10.00 сәгатьтә Буа шәһәре Башкарма комитеты бинасында ачык тыңлаулар үткәрергә.
6. Әлеге карарны ТР Буа муниципаль районы сайтында Интернет челтәрендә bua@tatar.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы мәгълүмат порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча 2020 елның 29 сентябренә кадәр бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе Р. Я. Галәветдиновка йөкләргә.

Буа муниципаль районы Буа шәһәре
башлыгы урынбасары С.А. Зайцева

Буа муниципаль районы Буа шәһәре башлыгының
2020 елның 22 сентябрендәге 10
номерлы карарына
1 нче кушымта

Ачык ( гавами) тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| 1. Галәветдинов Р.Я. | Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе, эшче төркем рәисе ( килешү буенча) |
| 2. Гыйззәтов И.Г. | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| 3. Гыйльфанов Р.М. | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура бүлеге башлыгы, эшче төркем рәисе урынбасары (килештерү буенча) |
| 4.Шакирҗанов Л.Р. | «Буа муниципаль районы «муниципаль берәмлегенең милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе (килешү буенча) |
| 5.Гимадиев И.И. | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советы депутаты (килешү буенча) |